| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА БИЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>ул.Центральная, д.46, с.Бизяки, Менделеевский район, Республика Татарстан, 423648 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ<br>Үзәк урам, 46 йорт, Бәзәкә авылы, Менделеевск районы, Татарстан Республикасы,423648 |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1 10.11.2025 ел

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 20 ноябре 10.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2025 елның 20 ноябре 13.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2025 елның 20 ноябре 16.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының өченче этабын билгеләргә.
4. Бәзәкә авыл җирлеге җыеннарының барлык этапларын уздыру урыны:

Беренче этап: Бәзәкә авылы, Яңа урам 1 йорт, авыл мәдәният йорты,

Икенче этап: Бәзәкә авылы, Үзәк урам, 46 йорт, административ бина,

Өченче этап: Бәзәкә авылы Яр буе урамы

5. Бәзәкә авылы халкы исемлеген җыен этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

Беренче этап: Яшьләр урамы, 1-126 йортлар, Елга аръягы урамы, 1-106 йортлар, Яңа урам, 1-36 йортлар.

Икенче этап: Үзәк урам, 1-102 йортлар

Өченче этап: Яр Буе урамы, 1-36 йортлар, Дуслык урамы, 1-14 йортлар, Бакча урамы, 1-11 йортлар, Рифкат Таҗиев урамы, 4,7 йортлар, Урман урамы, 10 йорт

6. Гражданнар җыенында түбәндәге сорауны расларга:

"2026 елда Сез үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан Сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, күпбалалы гаиләләрдән 50%ка киметеп 500 сум күләмендә, ә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?":

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;(илтеп җиткереп вак таш сатып алу, вак ташны

тигезләү, асфальт валчыклары сатып алу, Бәзәкә авылындагы юлларны кардан чистарту, узган елларның калган өлешләрен юлларны кардан чистартуга җибәрергә)
2. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; (су белән тәэмин итү системасы өчен бикләр сатып алу).
3. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Беларус 82.1 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, (запас частьләр, дизель ягулыгы сатып алу, тракторга асылмалы җайланмалар сатып алу), үлән чабу, агачлар кисү).
4. Урамнарны яктырту җайланмасы (Бәзәкә авылында яктырткычлар сатып алу). Бәзәкә авылында урамнарны яктырту җайланмасы).
5. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасын буяу өчен буяу сатып алу).
6. Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (Бәзәкә авылында рөхсәтсез чүплекләрне бетерү буенча хезмәт күрсәтүләр)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 10 көн эчендә мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Бәзәкә авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы _______ И.И. Кәшәфетдинов
(имза) (имзаны киңәйтү)